**ГЛАВА**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

2024 елның «01» ноябреннән　　　　　　　　　　　　　　　№ 37

2025 елга һәм 2026, 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2019 елның 24 октябрендәге 53-325 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмә»се, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-105 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә»се нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында яшәүчеләрнең 2025 елга һәм 2026, 2027 еллар план чорына Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты проекты турында фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «2025 елга һәм 2026, 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты турында» гы карары проекты буенча ачык тыңлауларны 2024 елның 20 ноябрендә 17:00 сәгатьтә Совет урамы, 80 йорт, Яңа Чишмә авылы, Яңа Чишмә районы, Татарстан Республикасы адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының актлар залында үткәрергә.

Ачык тыңлаулар тәртибе Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябреннән14-105 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы 2021елның 12 октябрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырылган нигезләмәгә туры китереп тормышка ашырыла.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «2025 елга һәм 2026, 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты турында» карары проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

3. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә «2025 елга, һәм 2026, 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне, гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә «2025 елга һәм 2026, 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проектын, гавами тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, эшләп бетерергә һәм 2024 елның 06 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы утырышында карауга кертергә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Башлык В.М. Козлов

Татарстан Республикасыи
Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгының
2024 елның«01» ноябреннән 37
номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «2025 елга һәм 2026, 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты турында» карары проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе

1. 2025 елга һәм 2026, 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты проектына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Совет ур., 80 йорт, 314 нче каб. адресы буенча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгына язма формада кертәләр.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. электрон адресы буенча урнаштырылган көннән алып эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80 каб. № 314 яки почта аша (конвертта «бюджет турында фикер алышу» тамгасы белән билгеләргә).